**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2023-2024 учебный год**
**7 КЛАСС**

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **а** | X | | X | X | | | | | | X | | | | *X* | *X* | | | | *X* | *X* |
| **ә** | | X | | | | | X | X | | | X | | *X* | | | | | *X* | | |
| **б** | | | | | X | | | | X | | | X | | | | | *X* | | | |
| **в** | | | | | | X | | | | | | | | | | *X* | | | | |
| | ***задания по 1 баллу*** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

1. Бирелгән мәкальдәге сузык авазларның саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)

Йокы – ялкауның бәлеше. (Мәкаль)
**а) 7;**
ә) 8;
б) 9;
в) 10.

2. Кайсы җөмләдә сыйфат фигыль бар? (1 балл)
а) Татарлар элек-электән хезмәт сөйгән.
**ә) Кечкенә чакта ясаган рәсемем хәзер дә саклана.**
б) Бу бизәкләр төсле җепләр белән чигелгән.
в) Газинур берничә адым алга йөгерергә өлгерде. (Г. Әпсәләмов)

3. Хезмәттәшлекнең сүзендә нинди мәънәле кисәкләр бар? (1 балл)
**а) тамыр, нигез, бер сүз ясагыч, бер модальлек, бер бәйләгеч кушымча;**
ә) тамыр, нигез, бер бәйләгеч кушымча;
б) тамыр, бер сүз ясагыч, ике модальлек кушымчасы;
в) тамыр, ике сүз ясагыч, бер бәйләгеч кушымча.

4. **“Үпкәләргә** саф һава тулды” һәм **“Үпкәләргә** җай чыгып кына тора” җөмләләрендәге билгеләнгән сүзләр ничек атала? (1 балл)
**а) саф омонимнар;**
ә) омоформалар;
б) омографлар;
в) омофоннар.

5. Тургай күккә күтәрелә, җыр яңгырый басуда (М. Җәлил) җөмләсендә күтәрелә фигыленең юнәлешен билгеләгез. (1 балл)
а) төшем юнәлеше;
ә) кайтым юнәлеше;
**б) төп юнәлеш;**
в) йөкләтү юнәлеше.

6. Бер авазны ике хәреф бергә белдерә торган сүзләр рәтен билгеләгез. (1 балл)
а) сәлам, шагыйрь, күзге;
ә) мәгънә, тәкъдим, дикъкать;
б) иртә, галим, кашык;
**в) яңа, юкә, сөенеч.**

7. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да басым соңгы иҗеккә төшә? (1 балл)
а) кайтма, дәфтәрне, авыл;
**ә) килдек, дәрестә, урындык;**
б) биемә, калын, кибеттән;
в) ничәнче, юка, уйлама;

8. Җөмләләрдән бәйләнешле текст барлыкка китерә торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
1. Әниләре балаларына ай буе сөтен имезде.
2. Керпе балаларын үстерү мәшәкате белән яшәде.
3. Берничә сәгать эчендә алар ап-ак йомшак энәләр белән капландылар.
4. Быел керпе дөньяга биш бала китерде.
5. Ә көз якынлашкач, аларны мөстәкыйль тормышка озатты.
6. Нәниләр ялангач тудылар, күзләре дә ачылмаган иде. (Г. Хәсәнов буенча)
а) 2,4,6,3,1,5.
**ә) 4,6,3,2,1,5.**
б) 3,5,4,6,2,1;
в) 4,5,3,2,1,6.

9. Сызык **ялгыш** куелган җөмләне билгеләгез. (1 балл)
а) Әнә киң болыннар, зур урманнар – һәммәсе яшәреп утыралар.
ә) “Дәрестә кемнәр юк?” – дип сорады укытучы.
**б) Бүген көн – җылы иде.**
в) Зөлфия – дәү әнисенең яраткан оныгы – җәйге каникулны авылда үткәрде.

10. Предмет яки төшенчәләрне атый торган кисәкне ачыклап,
аларның билгесен, кемгә яки нәрсәгә каравын белдерүче җөмлә кисәге –(1 балл)
**а) аныклагыч;**
ә) тәмамлык;
б) хәл;
в) аергыч.

11. Чәчәкләрнең акларына бал кортлары ешрак килеп куна (Г. Хәсәнов)
җөмләсендә сыйфатның үзгәрешен ничек атыйлар? (1 балл)
а) сыйфатның күплек белән төрләнүе;
**ә) сыйфатның исемләшүе;**
б) сыйфатның исемне алмаштыруы;
в) сыйфатның килеш белән төрләнүе.

12. Антоним сүзләр булган мәкальне билгеләгез. (1 балл)
а) Ике икең – дүрт.
ә) Уку – энә белән кое казу.
**б) Үпкә – дошман, акыл – дус.**
в) Теле татлының дусты күп.

13. Иренләшкән сузыклардан гына торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) [а], [ә], [ы], [э];
ә) [у], [ү], [о], [ә];
б) [и], [у], [э], [ә];
в) [о], [ы], [ә], [и].

14. Боерык фигыль нинди сорауларга җавап бирә?(1 балл)
**а) нишлә? нишләмә?**
ә) нишләргә? нишләмәскә?
б) нишли? нишләде?
в) ничек? кайчан?

15. Сөйләүче өчен билгелерәк булган әйбер турында әйткәндә, туры тәмамлык белдерелә: (1 балл)
**а) төшем килешендәге исем белән;**
ә) баш килештәге исем белән;
б) баш һәм төшем килешендәге исем белән;
в) теләсә кайсы килештәге исем белән.

16. Г. Тукайның “Милли моңнар” шигырендә лирик герой нинди көй ишетә? (1 балл)
а) “Тәфтиләү”
б) “Зиләйлүк”
**в) “Әллүки”**
г) “Гөлҗамал”

17. “Бүреләр” шигырен кем язган?
“Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.”
а)Ф.Кәрим
ә)С.Хәким
**б)М.Җәлил**
в)А.Пушкин

18. Һади Такташның “Алсу” әсәре нинди жанрда язылган?
Урам ташларына карлар ява,
Кар томалый чана юлларын,
Карда шуа-шуа Алсу килә,
Җиң эченә тыккан кулларын...
а)нәсер
**ә)поэма**
б)шигырь
в)бәет

19. Илгизәр кайсы әсәрнең герое?
**а) И.Гази «Йолдызлы малай»;**
ә)Г.Ибраһимов “Алмачуар”;
б) К.Насыйри “Әбугалисина”;
в) Г. Кутуй ”Рөстәм маҗаралары”;

20. Гипербола-
**а)әдәби әсәрдә предмет, күренеш, әйберне бик нык арттырып, зурайтып күрсәтү;**
ә) предметларның яки күренешләрнең үзлекләрен, билгеләрен, мәгънәләрен киметеп күрсәтү;
б) әдәби жанр;
в) әдәби алым,  җансыз предметларга җанлыларның үзлекләре бирелүе.

II. Атна исемнәрен татарча яз. (10 балл)
Понедельник- дүшәмбе
Вторник- сишәмбе
Среда-чәршәмбе
Четверг-пәнҗешәмбе
Пятница-җомга
Суббота-шимбә
Воскресенье-якшәмбе

III. Иҗади бирем. (10 балл)
Телевизор, компьютерлар белән
Чагыштырып булмый китапны.
Яшәр өчен акыл туплар Кеше,
Өстен куеп һәрчак китапны.
(Г. Гайнетдинова)
Сез бу шигырь юллары белән килешәсезме? Бүгенге көндә Сезнең өчен китапның кыйммәте нәрсәдә? Фикерләрегезне 10 җөмләдән торган текст итеп языгыз.
(10 балл)
Иҗади биремне бәяләү критерийлары:
1. Язма эшнең эчтәлеге темага туры килә – 2 балл
Язма эшнең стуктур элементлары (кереш өлеше, төп өлеше, нәтиҗә) төгәл күрсәтелгән - 3 балл
2. Орфографик хаталар 1-2 күп түгел- 2 балл
3. Пунктуацион хаталар 1-2 күп түгел – 1 балл
4. Логик хаталар юк- 1 балл
5. Фактик хаталар юк – 1 балл